**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 27 июне 1022 номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегендә 16:24:070801:4140 кадастр номерлы җир кишәрлегенә гавами сервитут билгеләү турында

РФ Җир кодексының 23 нче маддәсенең 4 пункты 1 пунктчасы нигезендә, җир кишәрлекләре милекчеләренең 2024 елның 27 апрелендәге 6959-АН номерлы мөрәҗәгатен, «Камская Новь» газетасында 2024елның 8 маендагы басмасында чыгарылган карарын һәм://laishevo.tatarstan.ru/hodataystva.htm сылтама буенча урнаштырылган Лаеш муниципаль районының сайттагы хәбәрен карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегендә кадастр номеры 16:24:070801:4140 булган җир кишәрлегенә кадастр номерлары 16:24:070801:436, 16:24:070801:708, 16:24:070801:2502, 16:24:070801:2501, 16:24:070801:3349 булган җир кишәрлекләренә керү һәм узуны оештыру максатларында гавами сервитут билгеләргә, билгеләү вакыты чикләнмәгән.
2. Керү яисә узу юлын урнаштыру максатларында гавами сервитутның кушымта итеп бирелә торган чикләрен расларга.
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә:

- әлеге карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

4. Мөрәҗәгать итүчеләргә:

- әлеге карарның күчермәләрен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, җир кишәрлекләренең хокук иясенә җибәрергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э. В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**